КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 март г.Казань № 236

Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1640 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 29 март, 236 нчы
карары белән расланды

Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы
көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен
финанслар белән тәэмин итү
тәртибе

1. Бу Тәртип социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм әлеге чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга күздә тотылган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге чараларны финанслар белән тәэмин итүгә акча җибәрә:

а) туберкулез микобактериясенең сизгерлеген ачыклау, билгеләү һәм авыру тудыручының бик күп даруларга тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны дәвалау мониторингы өчен Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлек нигезендә диагностика чаралары, шулай ук туберкулез белән авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибе белән күздә тотылган җиһазландыру стандарты нигезендә медицина әйберләре сатып алу;

б) кеше иммунодефициты вируслары белән, шул исәптән B һәм (яки) C гепатитлары вируслары катнашында йогышланган затларны ачыклау һәм дәвалау мониторингы өчен Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлек нигезендә диагностика чаралары сатып алу;

в) ВИЧ-инфекцияне, шулай ук ВИЧ-инфекция белән ассоциацияләнгән авыруларны профилактикалау мәсьәләләре буенча, шул исәптән коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларның әлеге чараларны тормышка ашыруга җәлеп итеп, гражданнарның мәгълүматлы булуын арттыру.

5. Акчаны сарыф итү Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

6. Финанслауның иң чик күләмнәре Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан ирештерелгәннән соң, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс

елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә ирештерә.

7. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрдә күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында:

бу Тәртипнең 4 нче пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларда:

социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясенең дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнары нигезендә дәүләт контрактлары төзи,

социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыру максатларында дәүләт контрактларын төзегән оешмаларга дәүләт контрактлары шартлары нигезендә акча күчерә;

бу Тәртипнең 4 нче пунктындагы «в» пунктчада:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИД һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (алга таба – медицина оешмасы) белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясындагы 1 нче пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасының дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь 17-148 нче боерыгы белән расланган форма буенча төзи,

медицина оешмасына субсидия күчерә.

8. Медицина оешмасы квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 5еннән дә соңга калмыйча, түбәндәге хисапларны Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча кертә:

социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчаны файдалану турында;

субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында.

9. Акчаны максатчан файдаланмау бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

10. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге очракларда медицина оешмасы тарафыннан бирелгән акчаның өлешчә яки тулысынча кире кайтарылуын тәэмин итә:

әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмасы тарафыннан дөрес булмаган хисаплар кертелгәндә;

медицина оешмасы тарафыннан акча максатчан файдаланылмаганда.

11. Бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән очракларда, медицина оешмасына бирелгән акча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән 15 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмасы тарафыннан акчаны кире кайтару вакытлары бозылган очракта, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацы белән билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән 30 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

12. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә кергән акчаны максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны тәэмин итә.

13. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы субсидияләрдән файдалану һәм субсидияне файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапларны Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнә торган вакытларда һәм формалар буенча Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә.

14. Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм медицина оешмасына законнар нигезендә йөкләнә.

15. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына акчаның файдаланылмый калган өлеше федераль бюджетка Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.